# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

№ 20 Кәрәкәшле ав. 2019 ел 28 октябрь

“Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенына әзерлек һәм аны уздыру тәртибе турында”гы Нигезләмәне раслау хакында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясын, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясын һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14 статьясын гамәлгә ашыру максатларында, Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Кушымта нигезендә "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге торак пунктларында гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында» Нигезләмәне расларга.
2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында «Нигезләмәне раслау хакында»2009 ел, 1октябрь, 16 нчы карары үз көчен югалткан дип санарга.
3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.
4. Аның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы: Г.М.Хәмидуллина

Кушымта
Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Советының 2019 елның 28 октябреннән булган 20 санлы карарына

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенына әзерлек һәм аны уздыру тәртибе турында Нигезләмә

ӘлегеТатарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Уставының 14 статьясы нигезендә эшләнде.

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Халык җыены гомуми, тигез һәм турыдан-туры ихтыяр белдерү нигезендә үткәрелә.

1.2. Гражданнар җыенында торак пунктта яшәүчеләр, даими яки күпчелек вакытта аның территориясендә яшәүчеләр, яшәү урыны буенча әлеге торак пунктта теркәлгән һәм сайлау хокукына ия кешеләр катнаша ала.

1.3. Гражданнар җыенында катнашу ирекле.

1.4. Һәрбер граждан җыенда шәхсән үзе катнаша һәм һәрбер граждан бер тавышка ия.

1.5. Гражданнар җыены халык тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне турыдан-туры хәл итү максатыннан үткәрелә.

1.6. Әгәр торак пунктта әлеге торак пунктта сайлау хокукына ия кешеләрнең яртысыннан артыгы бер үк вакытта бергә булу мөмкинлеге булмаса, Устав нигезендә гражданнар җыены этаплап уздырыла.

Гражданнар җыены вәкаләтләре

1.7. Гражданнар җыены түбәндәге мәсьәләләр буенча үткәрелергә мөмкин:

торак пунктта җирлек чикләрен үзгәртү соравы буенча, әгәр нинди дә булса торак пункт җирлек составына керсә һәм аны башка җирлек

(муниципаль район) территориясенә кертү мәсьәләсе каралганда; муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре күрсәтелгән җирлекнең чикләрен үзгәртү, үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча гражданнар җыены белән гамәлгә ашырыла торган җирлектә;

сайлау хокукына ия булган җирлектә яшәүчеләр саны 100 дән артык кеше булса, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органын төзү, аның саны һәм вәкаләтләр вакыты турында мәсьәлә буенча;

муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены белән гамәлгә ашырыла торган җирлектә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча;

җирлек составына керүче торак пунктта, шәһәр эчендәге район, федераль әһәмияттәге шәһәр эчендәге территориядә, шәһәр округында яисә муниципаль район чикләрендә урнашкан, авылара территориядә урнашкан торак пунктта әлеге торак пункт территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча;

җирлекара территориядә урнашкан торак пунктта, җирле үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру белән бәйле мәсьәләләр буенча халык инициативасын тәкъдим итү максатларында;

авыл җирлегенең тыгызлыгы түбән булган территориясендә яки халык саны 100 кешедән артмаган, үтүе авыр булган торак пунктта, җирлекне бетерү соравы буенча;

авыл торак пунктында авыл җирлеге старостасы кандидатурасын тәкъдим итү, шулай ук авыл җирлеге старостасы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату соравы буенча;

авыл торак пунктында гражданнар җыены шулай ук муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс үткәргәндә конкурс комиссиясе составына кандидатуралар тәкъдим итү максатларында үткәрелергә мөмкин.

Гражданнар җыенын матди һәм оештыру ягыннан тәэмин итү

1.8. Гражданнар җыенын уздыру муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан тәэмин ителә.

1.9. Җыенга әзерлек һәм аны үткәрү белән бәйле чыгымнар муниципаль берәмлек бюджеты хисабына башкарыла.

2. Гражданнар җыенын чакыру тәртибе

Гражданнар җыенын үткәрү инициативасы

2.1. Торак пунктта гражданнар җыенын үткәрү инициативасы түбәндәгеләрнеке була:

- муниципаль берәмлек башлыгыныкы;

- сайлау хокукына ия булган, гражданнар җыенында катнашырга хокуклы торак пунктта яшәүче, 10 кешедән дә ким булмаган (ягъни Россия Федерациясенең эшкә сәләтле гражданнары), даими яки күбесенчә торак пункт территориясендә яшәүче, яшәү урыны буенча әлеге торак пунктта теркәлгән, 18 яшькә җиткән гражданнар, шулай ук Россия Федерациясенең халыкара килешүләре һәм федераль законнар нигезендә җирле үзидарәне гамәлгә ашырганда хокукларга ия булган, торак пункт территориясендә даими яисә нигездә яшәүче һәм җирле үзидарәне гамәлгә ашырганда хокукка ия булган чит ил гражданнары.

2.2. Торак пунктта яшәүчеләрнең инициативасы имзалар кәгазе (1 нче кушымта) яисә инициатив төркем җыелышының җыен үткәрү инициативасын күрсәтү турында карар кабул ителгән беркетмәсе рәвешендә рәсмиләштерелергә тиеш, аларда түбәндәгеләр күрсәтелгән булырга тиеш:

гражданнар җыенына чыгарыла торган сораулар;

гражданнар җыенын үткәрүнең тәкъдим ителгән вакыты;

гражданнар җыенын чакыру турындагы инициативаны хуплаучы һәр гражданинның паспорт сериясе һәм номеры, яшәү урыны, аның имзасы һәм имзасын кертү датасы.

2.3. Җыенны үткәрү инициативасын хуплау өчен җыелырга тиешле имзалар саны сайлау хокукына ия булган, даими яки күпчелек вакытта биредә яшәүче, яшәү урыны буенча биредә теркәлгән гражданнар санының 5 процентын тәшкил итә, ләкин имзалар саны 10 (ун) имзадан да ким була алмый.

2.4. Имза куелган кәгазьләр имзалар җыючы зат тарафыннан раслана, раслау датасын, фамилиясен, атасының исемен, туган елын, паспорт номерын һәм сериясен, яшәү урынын күрсәтеп, муниципаль берәмлек башлыгына җибәрелә.

Гражданнар җыенын үткәрү турында карар кабул итү тәртибе

2.5. Инициатив төркем тарафыннан чакырыла торган гражданнар җыены муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән (*2 нче кушымта*), ә муниципаль берәмлек башлыгы инициативасы белән – муниципаль берәмлек башлыгы карары белән *(3 нче кушымта)* барлык кирәкле документлар кергән көннән 30 көн эчендә билгеләнә.

2.6. Муниципаль берәмлек башлыгы яисә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы аның максатка ярашлы булмавын сәбәп итеп, гражданнар җыенын үткәрүдән баш тартырга хокуклы түгел.

2.7. Гражданнар җыенына (гражданнар җыены этабына) чыгарылган сорау Россия Федерациясе законнарына һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килмәскә тиеш. Халык җыенына куелган сорау аны күп мәгънәле итеп аңлату мөмкинлегеннән чыгып куелырга тиеш түгел, ягъни аңа бер мәгънәле генә җавап бирелерлек итеп куелырга тиеш.

2.8. Гражданнар җыенын билгеләү, аны күчерү турындагы карарны рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) тәртибе муниципаль берәмлек уставы белән билгеләнә һәм муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен муниципаль берәмлек уставында каралган тәртиптә басылып чыга (халыкка җиткерелә).

Муниципаль берәмлек башлыгы карарында яисә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карарында гражданнар җыенын уздыру турында түбәндәгеләр күрсәтелә: гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәлә; гражданнар җыенын уздыру вакыты һәм урыны турында мәгълүмат; җыенны оештыручы-муниципаль берәмлек органының структур бүлекчәсе турында мәгълүмат.

2.9. Гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү өчен җаваплы муниципаль берәмлек органының структур бүлекчәсе (башкарма-боеру органы) муниципаль берәмлек башлыгы карары яки муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары нигезендә гражданнар җыенын үткәрү турында сайлау хокукына ия булган торак пунктта яшәүчеләр исемлеген төзи; гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерли; муниципаль берәмлек халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итә. *(№4 кушымта).*

Муниципаль берәмлекнең башкарма-боеру органы гражданнар җыенын үткәрү өчен бүлмә бирергә тиеш.

2.9.1. Гражданнар җыенын этаплап уздырганда, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлү һәм халык җыенын үткәрү датасын билгеләү территориаль, вакыт билгеләре, шулай ук башка очракларда мөмкин.

2.9.2. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне сайлау тәртибе гражданнар җыенын билгеләү турында муниципаль актта күрсәтелә (5,6 нчы кушымталар).

2.9.3. Торак пунктта яшәүчеләргә халык җыенын үткәрү вакыты һәм урыны турында алдан ук хәбәр ителә. Гражданнар җыенын билгеләү турындагы карар, гражданнар җыенын үткәрү вакыты һәм урыны гражданнар җыенына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча алдан

бастырылып чыгарылырга (халыкка игълан ителергә) тиеш. Гражданнар җыенының этапларын үткәрү вакыты һәм урыны бер карарда яисә халык җыенын билгеләү турында карарда күрсәтелә.

2.9.4. Халык җыенын этаплап уздырган очракта, җыен этаплап уздырыла, гражданнар җыенын үткәрү турында Карар кабул ителгән көннән бер айдан да артмаска тиеш. Халык җыены этапларын күчергәндә, җыенны уздыруны ккүчерү турында карар җыен билгеләнгән датага кадәр 10 көннән дә соңга ккалмыйча, ай дәвамында законнар нигезендә җыен үткәрелергә тиеш булган чорга кадәр кабул ителергә тиеш.

2.9.5. Гражданнар җыенында катнашучы һәр кеше җыен үткәрелгәнгә кадәр 5 көннән дә соңга калмыйча муниципаль берәмлек органының әлеге Нигезләмәнең 2.9 структур бүлекчәсендә күрсәтелгән гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышырга, шулай ук аларның күчермәләрен алырга хокуклы.

2.10. Гражданнар җыены турындагы Нигезләмәгә ярашлы, халык җыенын үткәрү датасы соңрак вакытка күчерелергә мөмкин. Халык җыенын уздыру датасын күчерү турында карар, билгеләнгән датага кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.

3. Гражданнар җыенын үткәрү тәртибе

3.1. Җыенга килгән гражданнар торак пунктта яшәүчеләр исемлегенә кертелгән һәм сайлау хокукына ия булган затларны теркәү өчен муниципаль берәмлек башлыгы вәкаләт биргән зат тарафыннан теркәлә. Исемлектә гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы, яшәү урыны, паспорт сериясе һәм номеры күрсәтелә.

3.2. Җыенда анда катнашырга теләк белдергән башка гражданнар хәлиткеч тавыш бирү хокукыннан башка катнаша ала, җыенда тикшерелә торган сорауларны хәл итү алар эшчәнлеге белән бәйле предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләре, матбугат һәм башка массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре дә катнашырга мөмкин.

3.3. Сайлау хокукына ия торак пунктта яшәүчеләр исемлегендә төгәлсезлекләр ачыкланган очракта, торак пунктта яшәүче кеше теркәлергә һәм әлеге муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан җыенда катнаштырылырга мөмкин.

3.4. Язмаларның төгәлсезлеген (яки аларның булмавын) раслаучы документ булып гражданның шәхесен раслаучы документ (Россия Федерациясе гражданины паспорты, хәрби билет, чит ил гражданы паспорты, Россия Федерациясендә яшәүгә рөхсәт, Россия Федерациясендә вакытлыча яшәүгә рөхсәт һәм башкалар булырга мөмкин) хезмәт итә ала.

3.5. Гражданнар җыены анда сайлау хокукына ия булган торак пунктта яшәүчеләрнең яртысыннан артыгы катнашканда тулы хокуклы була. Кворум булмаганда, гражданнар җыенын үткәрүнең яңа датасын билгеләү муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан башкарыла. Бу очракта халык җыены халык җыенын үткәрү билгеләнгән көннән соң ун көннән дә иртә үткәрелергә тиеш түгел.

3.6. Гражданнар җыены этаплап уздырылган очракта, гражданнар җыены җыенның аерым этапларында гражданнарның күпме санда килүе очрагында да тулы хокуклы, аннан соң барлык уздырылган этаплар йомгаклары буенча тавышлар санала, ягъни мондый җыен бердәм җыен дип исәпләнә.

3.7. Гражданнар җыенында тавыш бирү ачык яисә яшерен булырга мөмкин.

Тавыш бирү формасы турындагы карар гражданнар җыены тарафыннан кабул ителә (вариант буларак: форма гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә белән билгеләнә).

3.8. Гражданнар җыенында катнашу өчен теркәлгән гражданга яшерен тавыш бирүне уздырганда тавыш бирү өчен бюллетень бирелә (7 нче кушымта).

3.9. Гражданнар җыенында муниципаль берәмлек башлыгы яисә гражданнар җыенында катнашкан теркәлгән гражданнар арасыннан ачык тавыш бирү юлы белән сайланган башка зат рәислек итә ала. Рәислек итүче кандидатурасын гражданнар җыенында катнашучылар тәкъдим итәргә хокуклы.

3.10. Гражданнар җыены сәркатипне һәм хисап комиссиясен сайлый. Хисап комиссиясе әгъзалары саны өч кешедән дә ким булырга тиеш түгел. Хисап комиссиясенә рәислек итүче керә алмый.

Хисап комиссиясе:

халык җыенына килгән халыкның теркәлүе, кирәк булган очракта, аларның халык җыенында катнашу хокуклары дөреслеген тикшерә;

Халык җыенының кворумын билгели (гражданнар җыены этапларын үткәрүдән тыш));

тавыш бирү мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирә;

тавышларны саный һәм тавыш бирүгә йомгак ясый (гражданнар җыены этапларын үткәрүдән тыш));

тавыш бирү нәтиҗәләре турында беркетмә төзи (гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча);

рәислеккә тавыш бирү нәтиҗәләре белән материаллар (беркетмә, җыенда катнашучы гражданнар исемлеге) тапшыра.

3.11. Гражданнар җыенының көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләр рәислек итүче, муниципаль берәмлек башлыгы, гражданнар җыенында катнашу хокукына ия гражданнар тарафыннан кертелә ала. Көн тәртибенә чакырылыш инициаторлары тарафыннан кертелгән сораулар мәҗбүри рәвештә кертелә. Әлеге сораулар беренче чиратта карала. Халык җыенының көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләрне кертү турында карар, әгәр аның өчен җыенда катнашкан гражданнарның яртысыннан да ким булмаган өлеше тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.

3.12. Гражданнарның этаплап җыенын уздыру вакытында шулай ук муниципаль берәмлек башлыгы яисә ачык тавыш бирү юлы белән сайланган башка зат, гражданнар җыенында теркәлгән катнашучылар саныннан күпчелек тавыш белән, рәислек итә ала. Рәислек итүче кандидатураларын җыенда катнашучылар тәкъдим итәргә хокуклы.

3.13. Гражданнарның этаплап җыенында тавыш бирү ачык яисә ябык (яшерен) булырга мөмкин.

Тавыш бирү формасы турында карар гражданнар җыены этабында кабул ителә.

3.14. Этаплы гражданнар җыенын уздыру этапларында хисап комиссиясе арасыннан гражданнарның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча хисап комиссиясенең бер әгъзасы сайлап куела, алар кворумны һәм йомгаклау тавышларын санаганда комиссия составында эшләргә тиеш була.

3.15. Гражданнар җыены җыенда рәислек итүче тарафыннан ачыла. Гражданнар җыенында рәислек итүче гражданнар җыенын үткәрүне оештыра, тәртипне хуплый, хисап комиссиясе эшен координацияли, фикер алышына торган мәсьәләләр буенча чыгыш ясау өчен сүз бирә, тавыш бирүнең билгеләнгән тәртибен тәэмин итә.

3.16. Гражданнар җыенында сәркатип тарафыннан беркетмә алып барыла, анда гражданнар җыенын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны, торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны, сайлау хокукына ия гражданнар саны, катнашучылар саны, көн тәртибе, чыгышларның кыскача эчтәлеге, карала торган мәсьәләләр буенча тавыш биргән гражданнар саны (8 нче кушымта) күрсәтелә.

3.17. Халык җыенын этаплап уздырганда, гражданнар җыенының һәр этабында беркетмәләр (9,10 нчы кушымталар) алып барыла, алар алга таба гражданнар җыенының уздырылган этаплары йомгаклары буенча җыенның бер йомгаклау беркетмәсенә (11 нче кушымта), шулай ук Хисап комиссиясе беркетмәләренә (12,13 нче кушымталар) тутырыла, алар шулай ук

гражданнар җыенының һәр этабында тавышларны санау нәтиҗәләре буенча Хисап комиссиясенең бер йомгаклау беркетмәсенә (14 нче номерлы беркетмә) тутырыла.

3.18. Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсендә гражданнар җыены этапларының датасы, урыны һәм вакыты, көн тәртибе, гражданнар җыены этапларында катнашкан гражданнарның гомуми саны турында белешмәләр, гражданнар җыены этаплары нәтиҗәләре буенча тавыш бирүнең йомгаклау нәтиҗәләре булырга тиеш. Йомгаклау беркетмәсе җирлек башлыгы кул куя торган һәм соңыннан аны рәсми бастырып чыгару (халыкка игълан итү) белән гражданнар җыены карарын рәсмиләштерү өчен нигез булып тора.

3.19. Беркетмәгә җыенда рәислек итүче зат, җыен секретаре кул куя һәм ул муниципаль берәмлек башлыгына тапшырыла. Беркетмәгә җыенда теркәлгән катнашучылар исемлеге теркәлә.

3.20. Гражданнар җыенының уздырылган этаплары йомгаклары буенча Хисап комиссиясенең йомгаклау беркетмәсендә гражданнар җыены этапларын үткәрү датасы, урыны һәм вакыты, көн тәртибе, үткәрелгән этаплар саны, халык җыеннарының үткәрелгән этаплары буенча хисап комиссиясе беркетмәләре саны, җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче гражданнарның гомуми саны, җыен эшендә катнашкан гражданнарның гомуми саны, алар өчен бирелгән тавышларның гомуми саны, аңа каршы тавышларның гомуми саны булырга тиеш.

3.21. Йомгаклау беркетмәсенә Хисап комиссиясе рәисе һәм Хисап комиссиясе әгъзалары кул куя һәм муниципаль берәмлек башлыгына тапшырыла.

## 4. Гражданнар җыены карарлары

4.1. Гражданнар җыены карары, әгәр аның өчен сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучыларның яртысыннан артыгы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.

4.2. Җыенда кабул ителгән карарлар муниципаль хокукый актлар булып тора, муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан имзалана һәм Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелергә тиеш.

4.3. Җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары гражданнар җыенында кабул ителгән карарларның җирлек уставы белән билгеләнгән вәкаләтләрне чикләү нигезендә үтәлешен тәэмин итәләр.

4.4. Җыенда кабул ителгән карар җыенда башка карар кабул итү юлы белән юкка чыгарылырга яки үзгәртелергә мөмкин яки суд тәртибендә гамәлдә түгел дип танылырга мөмкин.

4.5. Гражданнар җыенында кабул ителгән карарлар рәсми бастырылып чыгарылырга (халыкка игълан ителергә) тиеш һәм муниципаль хокукый актларга кулган таләпләре нигезендә рәсмиләштерелә.

4.6. Әгәр торак пунктта яшәүчеләрне турыдан-туры ихтыяр белдерү юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру өчен өстәмә рәвештә муниципаль хокукый акт кабул итү (бастырып чыгару) таләп ителә икән, күрсәтелгән актны кабул итү (бастырып чыгару) аның компетенциясенә керә торган җирле үзидарә органы яисә җирле үзидарәнең вазыйфаи заты гражданнар җыенында кабул ителгән карар үз көченә кергән көннән соң 15 көн эчендә тиешле муниципаль хокукый актны әзерләү һәм (яисә) кабул итү вакытын билгеләргә тиеш. Күрсәтелгән срок өч айдан да артмаска тиеш.

Гражданнар җыены карарларын үтәү

4.7. Җыенда кабул ителгән карарлар торак пункт территориясендә мәҗбүри үтәлергә тиеш һәм нинди дә булса дәүләт хакимияте органнары, аларның вазыйфаи затлары яисә җирле үзидарә органнары тарафыннан раслануга мохтаҗ түгел.

4.8. Җыенда кабул ителгән карарларны үтәмәү закон нигезендә җавап тотуга сәбәп булып тора.

Кушымта 1

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль

районы Кәрәкәшле авыл җирлеге составына

керүче торак пунктларда гражданнар җыенын

әзерләү һәм уздыру тәртибе турында

Нигезләмәгә

ИМЗАЛАР КУЮ КӘГАЗЕ

Без, түбәндә имза куючылар, ____________________________________________________________

(гражданнар җыенын уздыру сроклары)
Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге _
____ торак пунктында __________________________________________ соравы буенча
гражданнар җыенын уздыру инициативасын хуплыйбыз

| № № т/б | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Туу датасы | Яшәү урыны адресы | Паспортның яки аны алыштыручы документның сериясе, номеры | Имзаны кую датасы | Имза |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Имзалар кәгазенраслыйм ________________________________________
(имзалар җыюны башкарган затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы,
_____________________________________________________________________________
Яшәү урыны, паспортының яки аны алыштыручы документының сериясе һәм номеры
______________________ (имза һәм дата)

Кушымта 2

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль
районы Кәрәкәшле авыл җирлеге составына
керүче торак пунктларда гражданнар җыенын
әзерләү һәм уздыру тәртибе турында
Нигезләмәгә

СОВЕТ КАРАКАШЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Каракашлы, ул.Мирфатиха Закиева, д.47 ,
423961

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Кәрәкәшле авылы, Мирфатыйх Зәкиев,
47 йорт, 423961

Тел.:(85593) 4-21-34, факс:4-21-21, e-mail: Karak.Utz@tatar.ru

**КАРАР**

**_______20**ел** **№ ____**

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге ______ торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану сораулары буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кәрәкәшле авыл җирлеге Уставының 14 статьясы нигезендә, Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. 20**елның _____нда Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге ________ торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

“Сез Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән (үзара салымнан азат ителгән гражданнар категориясен күрсәтергә – алардан тыш) 20__ елда ___ сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә ризамы?:

“РИЗА”                                   «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтына урнаштыру юлы белән 5 көн эчендә игълан итәргә.

3. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы            ФИАи   _________

Кушымта 3

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль
районы Кәрәкәшле авыл җирлеге составына
керүче торак пунктларда гражданнар җыенын
әзерләү һәм уздыру тәртибе турында
Нигезләмәгә

ГЛАВА КАРАКАШЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Мирфатиха Закиева, д.47,
с.Каракашлы, 423961

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Мирфатыйх Зәкиев урамы, 47йорт,
Кәрәкәшле авылы, 423961

Тел.:(85593) 4-21-34, факс:4-21-21, e-mail: Karak.Utz@tatar.ru

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башлыгы карары 20 ___ елның ___ N__ _

"Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану соравы буенча гражданнар җыенын билгеләү турында"

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Уставының 14 статьясы нигезендә, Ютазы муниципаль районының «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР ИТТЕ:

1. 20___ елның _____ нә Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең _____ торак пунктында үзара салым кертү соравы буенча гражданнар җыенын уздыруны билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешенең, ______ категорияләреннән тыш, 20_ _ елда ___ сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы ?

«РИЗА» “КАРШЫ".

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтына урнаштыру юлы белән _ _ _ _ көн эчендә игълан итәргә.

3. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

“Кәрәкәшле авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башлыгы ФИА

Кушымта 4

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә

________________________________ _______________________________
(муниципаль район исеме) (җирлек исеме)
____________(торак пункт исеме)
____________________ нда яшәүче сайлау хокукына ия булган яшәүчеләр

ИСЕМЛЕГЕ

«___» __________________ 20___ ел

| №№ т/б | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Туган елы (18 яше тулган зат – туган ае, көне) | Яшәү урыны адресы | Паспорт сериясе, номеры | Имза |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

Гражданнар җыенында рәислек итүче __________ ________________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)

Гражданнар җыены сәркатибе __________ ________________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)

Кушымта 5
Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль
районы Кәрәкәшле авыл җирлеге составына
керүче торак пунктларда гражданнар җыенын
әзерләү һәм уздыру тәртибе турында
Нигезләмәгә

СОВЕТ КАРАКАШЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Мирфатиха Закиева, д.47,
с.Каракашлы, 423961

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мирфатыйх Зәкиев урамы, 47йорт,
Кәрәкәшле авылы, 423961

Тел.:(85593) 4-21-34, факс:4-21-21, e-mail: Karak.Utz@tatar.ru

**_______20** ел КАРАР № ______**

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге _____ торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кәрәкәшле авыл җирлеге Уставының 14 статьясына ярашлы, Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге ______ торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 20**елның _____ на билгеләргә.

2. Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге торак пунктында үзара салым кертү соравы буенча гражданнар җыенының икенче этабын 20** елның _____ на билгеләргә.

3. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген (территориаль, вакытлыча яки башка билге буенча) сайлау тәртибе гражданнар җыенын билгеләү турында муниципаль актта күрсәтелә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

"Сез Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәчедән,

_____лардан тыш (үзара салымнан азат ителгән гражданнарны күрсәтергә) һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә ризамы?:

«РИЗА» “КАРШЫ”

5. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтына урнаштыру юлы белән 5 көн эчендә игълан итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көннән үз көченә керә.

Кәрәкәшле авыл җирлеге Башлыгы ФИАи ________

Кушымта 6

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль

районы Кәрәкәшле авыл җирлеге составына

керүче торак пунктларда гражданнар җыенын

әзерләү һәм уздыру тәртибе турында

Нигезләмәгә

ГЛАВА КАРАКАШЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Мирфатиха Закиева, д.47,
с.Каракашлы, 423961

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Мирфатыйх Зәкиев урамы, 47йорт,
Кәрәкәшле авылы, 423961

Тел.:(85593) 4-21-34, факс:4-21-21, e-mail: Karak.Utz@tatar.ru

---

“Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башлыгы карары _____ 20 ____ N__ _ _

"Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге _____ торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында"

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Уставының 14 статьясы нигезендә, Ютазы муниципаль районының «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР ИТТЕ:

1. Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының беренче этабын 20 __ елның _____на билгеләргә.

2. Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын 20 __ елның _____на билгеләргә.

3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне сайлау тәртибе (территориаль, вакыт яки башка билгеләр буенча) муниципаль берәмлек башлыгының гражданнар җыенын билгеләү турындагы карарында күрсәтелә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез 20__ елда Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән ____ сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны

алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?

“РИЗА” "КАРШЫ" .

5. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтына урнаштыру юлы белән 5 көн эчендә игълан итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

“Кәрәкәшле авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Башлыгы ФИАи ____

Кушымта 7

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль
районы Кәрәкәшле авыл җирлеге составына
керүче торак пунктларда гражданнар җыенын
әзерләү һәм уздыру тәртибе турында
Нигезләмәгә

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге составына керүче _____________торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча яшерен тавыш бирү

**БЮЛЛЕТЕНЕ**

| | | |
|---|---|---|
| Яшерен тавыш бирүгә куелган сорауның эчтәлеге | «Әйе» | ☐ |
| | «Юк» | ☐ |
| | | ☐ |

Кушымта 8

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль
районы Кәрәкәшле авыл җирлеге составына
керүче торак пунктларда гражданнар җыенын
әзерләү һәм уздыру тәртибе турында
Нигезләмәгә

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ БЕРКЕТМӘСЕ**

___________________________________________________________
(торак пунктның исеме )

«___» ____________ 20__ ел №_____

Катнаштылар _______________________________________________ кеше
(торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны, сайлау хокукына ия гражданнар саны, катнашучылар саны)

Гражданнар җыенында рәислек итүче ____________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Гражданнар җыены сәркатибе _____________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

**КӨН ТӘРТИБЕ:**

1.

2.

**ҖЫЕНДА РӘИСЛЕК ИТҮЧЕ САЙЛАНА :**

1. Иванова Светлана Ивановна-ФАП мөдире

Тавыш бирү нәтиҗәләре:

“Риза” _________ кеше
“Каршы” ________ кеше

**ҖЫЕН СЕКРЕТАРЕ САЙЛАНА:**

**Рәислек итүче:** җыен секретарен сайларга кирәк. Нинди тәкъдимнәр булачак?

ФИАи - вазыйфасы - секретарь итеп сайлау тәкъдиме дә бар

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
“Риза” _________ кеше
“Каршы” ________ кеше

## ҖЫЕННЫҢ ХИСАП КОМИССИЯСЕ САЙЛАНА:

Рәислек итүче: гражданнар җыены кворумын билгеләү, тавыш бирү мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирү, тавышларны санау һәм тавыш бирүгә йомгак ясау, тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзү өчен хисап комиссиясен сайларга кирәк.

Хисап комиссиясе рәисе итеп ФИАи һәм хисап комиссиясе әгъзаларын сайлау тәкъдиме бар:

1. Иванов Иван Ивановичны -
2. Петрова Полина Петровнаны –

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
“Риза” _________ кеше
“Каршы” ________ кеше

## КӨН ТӘРТИБЕНДӘГЕ СОРАУ БУЕНЧА ТАВЫШ БИРҮ ТӘРТИБЕ БИЛГЕЛӘНӘ:

**Рәислек итүче:** көн тәртибендәге мәсьәлә буенча тавыш бирү формасын билгеләү зарур. Тавыш бирү ачык яисә ябык (яшерен) булырга мөмкин. Тавыш бирүне уздыру формасы турында тәкъдим әйтелә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
“Риза” ___ кеше
“ Каршы” ____ кеше

## КӨН ТӘРТИБЕ БУЕНЧА ЭШ:

**Беренче сорау буенча тыңланды:**
_____________________________________________
(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки доклад тексты теркәлә)

**Чыгыш ясадылар:** 1. _____________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яки чыгыш тексты (теркәлә) һ.б.ш. (чыгыш ясаган гражданнар саны буенча)…

**КАРАР ИТЕЛДЕ:** (карарның эчтәлеге)

Тавыш бирү нәтиҗәләре: «РИЗА» - ____ кеше

«КАРШЫ” - ____ кеше

Карар _________________________

кабул ителде (кабул ителмәде)

**Икенче сорау буенча тыңланды:**

___________________________________________

(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

(чыгышның кыскача язмасы яки доклад тексты теркәлә)

**Чыгыш ясадылар:** 1. ___________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

(чыгышның кыскача язмасы яки чыгыш тексты (теркәлә) һ.б.ш. (чыгыш ясаган гражданнар саны буенча)…

**КАРАР ИТЕЛДЕ:** (карарның эчтәлеге)

Тавыш бирү нәтиҗәләре : «РИЗА» - ____ кеше

«КАРШЫ» - ____ кеше

Карар _________________________

кабул ителде (кабул ителмәде)

Гражданнар җыенында рәислек итүче ________ _______________

(имза) (имзаның расшифровкасы)

Гражданнар җыены секретаре ________ _______________

(имза) (имзаның расшифровкасы)

Кушымта 9

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль
районы Кәрәкәшле авыл җирлеге составына
керүче торак пунктларда гражданнар җыенын
әзерләү һәм уздыру тәртибе турында
Нигезләмәгә

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЭТАБЫ БЕРКЕТМӘСЕ**

_______________________________________________________

(торак пункт исеме)

«___» ____________ 20__ ел 00 сәгать 00 минут № __1___

Катнаштылар _____________________________________________ кеше

(торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны, сайлау хокукына ия гражданнар саны, катнашучылар саны)

Халык җыенында рәислек итүче _________________________________

(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

Халык җыены секретаре __________________________________________

(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

**КӨН ТӘРТИБЕ:**

1.

2.

**ҖЫЕНДА РӘИСЛЕК ИТҮЧЕ САЙЛАНА:**

2.Иванова Светлана Ивановна - ФАП мөдире

Тавыш бирү нәтиҗәләре:

“Риза” ____ кеше

“Каршы” ____ кеше

**ҖЫЕН СӘРКАТИБЕ САЙЛАНА:**

Рәислек итүче: җыен секретарен сайлау зарур. Нинди тәкъдимнәр булачак?

Секретарь итеп ФИАи - вазыйфасы сайлау тәкъдиме бар.

Тавыш бирү нәтиҗәләре:

“Риза” - ______ кеше

“Каршы” _____ кеше

**ҖЫЕННЫҢ ХИСАП КОМИССИЯСЕ САЙЛАНА:**

**Рәислек итүче:** гражданнар җыены кворумын билгеләү, тавыш бирү мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирү, тавышларны санау һәм тавыш бирүгә йомгак ясау, тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзү өчен хисап комиссиясен сайларга кирәк.

Хисап комиссиясе рәисе итеп _____ФИАи һәм хисап комиссиясе әгъзаларын сайлау тәкъдиме бар:

3. Иванов Иван Ивановичны -

4. Петрова Полина Петровнаны –

һ. б.

Тавыш бирү нәтиҗәләре:

“Риза” _____ кеше

“ Каршы” ____ кеше

**КӨН ТӘРТИБЕНДӘГЕ СОРАУ БУЕНЧА ТАВЫШ БИРҮ ТӘРТИБЕ БИЛГЕЛӘНӘ:**

**Рәислек итүче:** көн тәртибендәге сорау буенча тавыш бирү формасын билгеләргә кирәк. Тавыш бирү ачык яисә ябык (яшерен) булырга мөмкин. Тавыш бирүне уздыру формасы турында тәкъдим кертелә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре:

“Риза” _____ кеше

“ Каршы” ____ кеше

**КӨН ТӘРТИБЕ БУЕНЧА ЭШ:**

**Беренче сорау буенча тыңланды:**

___________________________________________________

(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

(чыгышның кыскача язмасы яки доклад тексты (кушымта итеп бирелә)

**Чыгыш ясадылар:** 1. ___________________________________________________

(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

(чыгышның кыскача язмасы яки чыгыш тексты (кушымта итеп бирелә))

һ. б. (чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)

**Карар ителде: (карар эчтәлеге)**

Тавыш бирү нәтиҗәләре: "   Риза» -  ____  кеше.

"Каршы»  - _____ кеше.

**Икенче сорау буенча тыңланды:** ______________________________

(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

(чыгышның кыскача язмасы яки доклад тексты (кушымта итеп бирелә))

**Чыгыш ясадылар:** 1. ___________________________________________________

(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

(чыгышның кыскача язмасы яки чыгыш тексты (кушымта итеп бирелә)

һ. б. (чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)…

**Карар иттеләр: (карарның эчтәлеге)**

Тавыш бирү нәтиҗәләре: "Риза» -__   кеше.

"Каршы» -___ кеше.

**Рәислек итүче:** йомгаклау карарының нәтиҗәсе гражданнар җыенының үткәрелгән этапларының тавышларын санау нәтиҗәләре буенча _____ җирлегенең _____ Уставы нигезендә рәсми рәвештә басылып чыгачак (халыкка җиткереләчәк).

Гражданнар җыенында рәислек итүче _________ __________________

(имза) (имза расшифровкасы)

Гражданнар җыенының секретаре _________ __________________

(имза) (имза расшифровкасы)

Кушымта 10

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль

районы Кәрәкәшле авыл җирлеге составына

керүче торак пунктларда гражданнар җыенын

әзерләү һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә

**ХАЛЫК ҖЫЕНЫНЫҢ ИКЕНЧЕ ЭТАБЫ БЕРКЕТМӘСЕ (һ. б.)**

_____________________________________________________________

(торак пункт исеме)

«___» _____________ 20__ ел 00 сәгать 00 минут № _2___

Катнаштылар __________________________________________ кеше

(торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны, сайлау хокукына ия гражданнар саны, катнашучылар саны)

Гражданнар җыенында рәислек итүче

__________________________________________

(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

Гражданнар җыены секретаре _____________________________________________

(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

**КӨН ТӘРТИБЕ:**

1.

2.

**ҖЫЕНГА РӘИСЛЕК ИТҮЧЕ САЙЛАНА:**

3.Иванова Светлана Ивановна - ФАП мөдире

Тавыш бирү нәтиҗәләре:

“Риза” ______ кеше

“ Каршы” _____ кеше

**ҖЫЕН СӘРКАТИБЕ САЙЛАНА:**

**Рәислек итүче:** җыен секретарен сайлау зарур. Нинди тәкъдимнәр булыр?

Секретарь итеп ФИАи -вазыйфасы сайлау тәкъдиме бар.

Тавыш бирү нәтиҗәләре:

“Риза” ______ кеше

“ Каршы” _____ кеше

**ҖЫЕННЫҢ ХИСАП КОМИССИЯСЕ САЙЛАНА:**

**Рәислек итүче:** гражданнар җыены кворумын билгеләү, тавыш бирү мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирү, тавышларны санау һәм тавыш бирүгә йомгак ясау, тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзү өчен хисап комиссиясен сайларга кирәк.

Хисап комиссиясе рәисе итеп ____________ФИАи һәм хисап комиссиясе әгъзаларын сайлау тәкъдиме бар:

1. Иванов Иван Ивановичны -
2. Петрова Полина Петровнаны –

һ. б.

Тавыш бирү нәтиҗәләре:

“Риза” ______ кеше

“ Каршы” _____ кеше

**КӨН ТӘРТИБЕНДӘГЕ СОРАУ БУЕНЧА ТАВЫШ БИРҮ ТӘРТИБЕ БИЛГЕЛӘНӘ:**

**Рәислек итүче:** көн тәртибендәге мәсьәлә буенча тавыш бирү формасын билгеләргә кирәк. Тавыш бирү ачык яисә ябык (яшерен) булырга мөмкин. Тавыш бирүне уздыру формасы турында тәкъдим яңгырады.

Тавыш бирү нәтиҗәләре:

“Риза” ______ кеше

“ Каршы” _____ кеше

**КӨН ТӘРТИБЕ БУЕНЧА ЭШ:**

**Беренче сорау буенча тыңланды:**

________________________________________________

(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

(чыгышның кыскача язмасы яки доклад тексты (кушымта итеп бирелә)

**Чыгыш ясадылар:** 1. ________________________________________________

(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

(чыгышның кыскача язмасы яки чыгыш тексты (кушымта итеп бирелә))

һ. б. (чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)

Тавыш бирү нәтиҗәләре: " Риза» - ____ кеше.

"Каршы» - _____ кеше.

**Икенче сорау буенча тыңланды:** ____________________________

(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

(чыгышның кыскача язмасы яки доклад тексты (кушымта итеп бирелә))

**Чыгыш ясадылар:** 1. ________________________________________________

(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

(чыгышның кыскача язмасы яки чыгыш тексты (кушымта итеп бирелә)

һ. б. (чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)…

Карар иттеләр: (карарның эчтәлеге)

Тавыш бирү нәтиҗәләре: "Риза» -__ кеше.

"Каршы» -___ кеше.

**Рәислек итүче:** йомгаклау карарының нәтиҗәсе гражданнар җыенының үткәрелгән этапларының тавышларын санау нәтиҗәләре буенча _____ җирлегенең _____ Уставы нигезендә рәсми рәвештә басылып чыгачак (халыкка җиткереләчәк).

Гражданнар җыенында рәислек итүче _________ __________________

(имза) (имза расшифровкасы)

Гражданнар җыенының секретаре _________ __________________

(имза) (имза расшифровкасы)

Кушымта 11
Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль
районы Кәрәкәшле авыл җирлеге составына
керүче торак пунктларда гражданнар җыенын
әзерләү һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә

**УЗДЫРЫЛГАН ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ ЭТАПЛАРЫ НӘТИҖӘЛӘРЕ БУЕНЧА ЙОМГАКЛАУ БЕРКЕТМӘСЕ**

______________________________________________________________

(Татарстан Республикасы муниципаль районы торак пункты исеме)

«___» ____________ 20__ ел 00 сәгать 00 минут № ____

20___ елның ______ нан гражданнар җыенының беренче этабы №1 беркетмәсенә (рәислек итүче ФИО), 20___ елның ______ нан гражданнар җыенының икенче этабы №2 беркетмәсенә (рәислек итүче ФИО) __________ сораулары буенча этаплап гражданнар җыеннары үткәрелде.)

1. Үткәрелгән җыен этаплары саны, тавыш бирү формасын күрсәтеп (ачык, яки ябык (яшерен)_______

2. Этаплап уздырылган гражданнар җыеннарының тәкъдим ителгән беркетмәләре саны ______

3. Җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм аларның эшендә катнашырга хокукы булган гражданнарның гомуми саны __________;

4. Сайлау хокукына ия һәм гражданнар җыены этапларында катнашкан гражданнарның гомуми саны___________

**Карар ителде:** (карар эчтәлеге)

- Гражданнар җыены этапларында кертелгән сорау өчен **"РИЗА"** дип бирелгән тавышларның гомуми саны _________;
- Кертелгән **"КАРШЫ"** дип бирелгән тавышларның гомуми саны _______

**КАРАР:** кабул ителде (сәбәпләрен күрсәтеп, кабул ителмәде)

Рәислек итүче (җирлек Башлыгы): ______ _________________
(имза) (имза расшифровкасы)

Сәркатип: ________ _________________
(имза) (имза расшифровкасы)

Кушымта 12
Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль

районы Кәрәкәшле авыл җирлеге составына

керүче торак пунктларда гражданнар җыенын

әзерләү һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЭТАБЫНЫҢ ХИСАП КОМИССИЯСЕ БЕРКЕТМӘСЕ

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшлеавыл җирлеге составына керүче ___________ торак пунктындагы тавыш бирү нәтиҗәләре турында

«_____» _______ 2019 ел №1

Ютазы муниципаль районы

Кәрәкәшлеавыл җирлеге торак

пунктының исеме

**Катнашалар:** хисап комиссиясе әгъзалары

1. ФИАи;

2. ФИАи;

3. ФИАи һ. б.

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия булган _______ граждан катнашты.

Көн тәртибе соравы буенча гражданнар җыенының беренче этабы буенча тавыш бирү нәтиҗәләре:

«_________________________________________________________________»

**“РИЗА”________тавыш**

**“КАРШЫ” ______ тавыш**

Хисап комиссиясе рәисе ФИАи

Хисап комиссиясе әгъзалары: ФИАи
ФИАи

Кушымта 13

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль

районы Кәрәкәшле авыл җирлеге составына

керүче торак пунктларда гражданнар җыенын

әзерләү һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫНЫҢ ИКЕНЧЕ ЭТАБЫНЫҢ ХИСАП КОМИССИЯСЕ БЕРКЕТМӘСЕ

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшлеавыл җирлеге составына керүче ___________ торак пунктындагы тавыш бирү нәтиҗәләре турында

«_____» _______ 2019 ел №2

Ютазы муниципаль районы

Кәрәкәшлеавыл җирлеге торак

пунктының исеме

Катнашалар: Хисап комиссиясе әгъзалары

1. ФИАи;

2. ФИАи;

3. ФИАи һ. б.

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия булган _______ граждан катнашты.

Көн тәртибе соравы буенча гражданнар җыенының икенче этабы буенча тавыш бирү нәтиҗәләре:

«____________________________________________________________________»

**“РИЗА”________тавыш**

**“КАРШЫ” ______ тавыш**

Хисап комиссиясе рәисе ФИАи

Хисап комиссиясе әгъзалары: ФИАи
ФИАи

Кушымта 14

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль

районы Кәрәкәшле авыл җирлеге составына

керүче торак пунктларда гражданнар җыенын

әзерләү һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы ______ җирлегенең _______ (торак пункт исеме) халык җыенының беренче һәм икенче этаплары буенча тавыш бирү нәтиҗәләре турында КОМИССИЯ БЕРКЕТМӘСЕ**

«___» ___________ 20__ ел _________________________________

(торак пунктның исеме)

Гражданнар Җыенының беренче, икенче (һ. б.) этаплары нәтиҗәләре ______________________________________________________________________________

(территориянең исеме ______________________________________________________________________________

муниципаль берәмлегенең яисә аның өлешенең)

Гражданнар Җыенының этапларын үткәрү датасы һәм вакыты: _______________ _____________ 20__ ел

Гражданнар җыеннарында тавыш биргәндә тавышларны санау нәтиҗәсендә : ______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

**Хисап комиссиясе билгеләде:**

Халык җыенының үткәрелгән этаплары саны ___________________________________________;

Гражданнар җыенының үткәрелгән этапларының Хисап комиссиясе беркетмәләренең тәкъдим ителгән саны ______;

Җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм җыен эшендә катнашырга хокуклы гражданнарның гомуми саны__________;

Җыен эшендә катнашкан гражданнарның гомуми саны __________________;

Гражданнар җыенына кертелгән сорау “РИЗА” дип бирелгән тавышларның гомуми саны _______;

Гражданнар җыенына кертелгән (-ов) сорауларга “КАРШЫ” дип бирелгән тавышларның гомуми саны.

**КАРАР ИТЕЛДЕ:**

1. ________ соравы буенча тавыш бирү нәтиҗәләрен расларга, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы

131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясы 6 өлеше нигезендә әлеге сорау буенча җыенны кабул ителгән дип санарга.

Хисап комиссиясе рәисе ______________________ ________________
(фамилиясе, инициаллары) (имза)
Хисап комиссиясе әгъзалары 1. __________________ ________________
(фамилиясе, инициаллары) (имзалары)
3.__________________ _____________
(фамилиясе, инициаллары) (имзалары)

Беркетмә төзелде «___» ______________ 20___ ел